| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2025 г. Казань № 663-4/соц-2025

Психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәт күрсәтүгә 2026 елга тариф билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү» 2022 елның 19 декабрендәге 1366 номерлы, «Коммерциясез оешмалар тарафыннан психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү» сынау проектын 2023 һәм 2024 елларда гамәлгә ашыру турында» 2023 елның 18 июлендәге 860 номерлы, «2026 елга психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башына финанслау нормативын раслау турында» 2025 елның 8 декабрендәге 1060 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 18.12.2025 ел, №34-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәт күрсәтүгә тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 663-4/соц-2025
карарына кушымта

Психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәт күрсәтүгә 2026 елга тариф

| № | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф |
|---|---|---|---|
| 1. | Психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәт күрсәтү | сум/сәгать | 79,00 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге